ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.12.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3374**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ««Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге 1513 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Административ регламентларны актуальләштерү максатларында, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 02 декабрендәге «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 411 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1415 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ««Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге 1513 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 12 нче кушымтасындагы 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алган яисә гаиләдә опека яки попечительлеккә караган, шул исәптән тәрбиягә алган гаиләне яки Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда, патронат гаиләне дә кертеп, үзенең бертуган абыйсы һәм (яисә ) апасы ( атасы йә анасы уртак булган абыйлары (яисә) апалары, уллыкка (кызлыкка) алынган) , әлеге баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) опекуннар (попечительләр) булган балалар, яисә шушы баланың опекуннары (попечительләре) ата-аналар (законлы вәкилләр) булган балалар белән белем ала торган төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия, "Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм "Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр

кертү хакында" 2022 елның 21 ноябрендәге 465-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш. »;

1.2. Административ регламентның 3.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында һәр юлын тутыру процессында формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формаль-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм порталда автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юллары ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә.».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары-Мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин